
# Мәктәп хәбәрчесе

**№8 (№39) октябрь 2022 ел**

Түбән Майна урта мәктәбе газите

Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru


/Мөхәррир минбәре/




## Саклангганны саклармын дигән...

Соңгы елларда тормышыбыз никадәр матур булмасын, еш кына күңелсезлекләргә дучар булабыз. Экстремизм, террорчылык актлары турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша еш ишетергә туры килә. Фаҗигаләр кайбер урында планлаштырган, кайбер урында кешенең тирә-якка битарафлыгыннан, ә кайсыберләре безнең игътибарсызлыгыбыздан килеп чыга. Ничек кенә булса да, нигездә кеше гомере өчен куркыныч тудыра торган хәлләрне булдырмый калуга үзебез дә өлеш кертә алабыз. Очраклы булмаган бу вакыйгалар һәркемнән икеләтә уяулыкны, игътибарлылык-ны һәм саклыкны таләп итә. Бу уңайдан нинди саклык чаралары күрелә, тәртип сакчылары алдында нинди бурычлар куела.

Гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан очракта үз вакытында чаралар күрү максатыннан, мәгариф учреждениеләрендә һәрвакыт өйрәнүләр, әңгәмәләр, рейдлар оештырылып тора. Оешма җитәкчеләренә үз эшчеләре белән, профилактика максатыннан, инструктажлар үткәрү бурычы йөкләнде. Оешмаларга, мәктәпләргә чит кешеләрне бары тик махсус журналларга теркәп, ныклы контрольгә алгач кына үткәрү тәртибе кертелгән. Ишек янында торучы вахта хезмәте булдырылган. Ләкин әле моның белән генә тукталып калырга ярамый, тагын бер кат искәртеп узабыз, барыбыздан да сизгерлек, уяулык сорала.

Без хәвефсезлек чараларын тагын да камилләштерер өчен мәктәптә төрле куркыныч хәлләрдән саклану өчен өйрәнүләр алып барабыз. Янгын вакытында бинадан чыгу юлларын, үзеңне тоту кагыйдәләрен кабатлатып торабыз. Теракт куркынычы булганда озын сигналдан соң, я булмаса шик тудыра торган күренешләрдән соң сыйныф бүлмәләрендә калуны, бикләнүне таләп итәбез.

Тагын бер мөһим булган, зур игътибар сорый торган хәвеф чыганагы-интернет бар. Файдалы ягыннан караганда, газизләребезгә куркыныч янавы да мөмкин. Әти-әниләр дә балаларының нәрсә белән кызыксынуын даими күзәтеп торсыннар иде. Бала нинди интернет сайтларында утыра, кемнәр белән, нинди темаларга аралаша – болар игътибардан читтә калмасын. Чөнки балалар тәҗрибәсез килеш социаль төркемгә керү сәбәпле, чит кешеләр, террористлар корбаны булырга мөмкиннәр. Шуңа күрә, берлектә эшчәнлек алып барсак кына, аларның иминлегенә ирешербез.

*Фәнүзә Гафиятуллина, "Мәктәп хәбәрчесе "мөхәррире*

## Укытучылар көне белән!



*Бәйрәмегез белән, хөрмәтле укытучылар!*

*Мәктәп еллары кеше гомерендә аерым бер чор ул. һәркемнең киләчәгенә бара торган юллар гади мәктәптән башлана. Укытучыларыбыз бар көчен һәм вакытын биреп дөньяны танырга өйрәтә. Барысына да түземлек, сабырлык һәм балаларны ярату кирәк. Әйе, укытучы һөнәре ул җанны дәвалаучы кебек. Ул күңелләребезне үстерүче, калебебезне тәрбияләүче. Сезгә бары тәрбияле һәм тырыш укучылар телибез. Аларның мәхәббәтен яулап, сәламәтлек белән эшләвегезне, безгә белем бирүегезне теләп калабыз.*

*"Мәктәп хәбәрчесе" редколлегиясе*

/Рәсми хәбәрләр/

## Беренче чирек нәтиҗәләре

28 нче октябрь көнне 2022/2023 нче уку елының I чиреге тәмамланды. 46 укучының 37 нә чирек билгеләре чыгарылды. Нәтиҗәләр буенча, 3 отличник: II сыйныфтан **Закиров Инсаф**, V сыйныфтан **Закирова Ләйсән**, VI сыйныф **Гафиятуллин Фаил**. Гомуми нәтиҗәләргә килгәндә, белем сыйфаты 59,4% тәшкил итте. Бу чиректә барлык сыйныфларда күп фәннәрдән ВПР (бөтенроссия тикшерү эшләре) уздырылды. Шулай ук, узган чиректә олимпиадаларның мәктәп туры башланды. Биремнәрне уңышлы үтәгән укучылар II чирек барышында район турында катнашачак.

*Илдар Сафиуллин, уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары*

/Безнең сәяхәтләр/



## Әдәмсуы каласында булдык

Мәктәптә куелган тәртип буенча, ел саен көзге табигатьне күзәтеп, аның "тавышын" тыңлап кайтабыз. Туган ягыбызның сурәтләп бетергесез матурлыгын күреп хозурланабыз. Табигать манзарасын, аның хуш исен дә бер генә рәссам да сурәтләп бирә алмас иде.

Быел без әле беркайчан да барырга туры килмәгән, тарихи әһәмияткә ия булган урынга бардык. Ул Әдәмсуы елгасы буенда урнашкан борынгы кала урыны. Рафик абый безгә бу урынның тарихын болай аңлатты: Тарихчылар фикеренчә, Әдәмсуы каласы 12-13 нче гасырларда төзелгән ныгытма булып санала. Ул Болгар дәүләтенең башкаласы Биләр шәһәре тирәсендәге саклану корылмаларының бер буынын тәшкил иткән. Каланың тирәсе чокыр һәм вал белән әйләндереп алынган. Аннан төньяк тарафта, Иске Татар Әдәмсуы авылы белән кала арасындагы җирдә шул чорга караган авыл урыны да билгеле. Каладан көньякка китеп, Яңа Чуаш Әдәмсуы авылы янында 1346-1347 нче елда вафат булган кеше каберенә куелган кабер ташы сакланган. Безнең тирәдә Әдәмсуы каласы кебек ныгытма Түбән Майнаның Югары кырында бар.

Инде сәяхәтебезгә әйләнеп кайтсак, без килеп җиткәнче укытучы абыйлар чатырларны корып, казаннарны асып куйганнар иде. Көн салкынча булганлыктан, кече сыйныф укучылары килүгә үк палаткаларга кереп урнаштылар. Алып килгән тәм-томнары белән тамак ялгап алгач, балалар төрле хәрәкәтле уеннар уйнадылар. Ул арада укытучы апалар тәмле итеп уха ашы пешерделәр, кыр җимешләре салып компот кайнаттылар.

Табигатьтәге ял вакыты бик тиз уза шул. Төш узгач чатырларыбызны җыеп, утырган урыннарыбызны да чистартып кайтырга әзерләндек. Хәзерге чор балалары күп вакытларын телефон һәм компьютер артында уздырып, ачык һавада хәрәкәтле уеннарны сирәк уйныйлар. Безгә хәзер кумердә пешкән бәрәңге тәме дә ятрак, чөнки пакетка тутырылган чипсыны ешрак ашыйбыз. Чын уеннар, чын ризыклар һәм чын дуслар менә шундый елларда гына буладыр дип уйлыйм.

*Самат Гафиятуллин, IX сыйныф укучысы*

/Мәктәп тормышы/







## "Дуслык" сыйныф сәгате

Октябрь аенда башлангыч сыйныфларда "Чын дуслык" дигән дәрестән тыш чара уздырылды. Бу психологик атналык программасы буенча үткәрелде. Укучылар сыйныф сәгатьләрендә төрле тренинглар үттеләр. Чын дуслыкның нинди икәнлеген аңлаткан төшенчәләрне үзләштерделәр. Баштан алар "Тату өй" дигән әкият тыңладылар. Әкияткә анализ ясаганнан соң, дуслыкның нигезен билгеләделәр. Монда һәр укучы үз фикерен белдерде. Аннан соң балалар Сукыр һәм Алып баручы дигән уен уйнадылар. Чиратлашып, күзләрне бәйләп, сукыр ролендә дә булдылар. Сукырга, әлбәттә, каршылыкларны узу авыр булганын, ә күргән кешегә җиңел икәнен аңладылар. Укучыларыбыз дусларын кыенлыкларда калдырмаска, шул авырлыкларны җиңәргә ярдәм итәргә тиешлелегенә төшенделәр. Ахырдан Дуслык агачы ясадылар. Бу агач аларның учларын рәсемгә төшерүдән гыйбарәт иде. Уч – дуслык символы. Чөнки күрешкәндә дә без яхшы теләкләр теләп кул биреп күрешәбез. Укучылар дус булып, бер-берсенә ярдәмләшеп яшәсә, алдагы тормышлары күпкә уңышлырак булыр.

*Гөлшат Закирова, башлангыч сыйныфлар укытучысы*

/Безнең уңышлар/

## Вика – Татарстанда икенче!

21 нче октябрь көнне XI сыйныф укучысы **Нукина Вика** бөек рус язучысы Лев Толстой исемендәге **XX республикакүләм фәнни-гамәли конференциядә** катнашты. Толстойның тормыш юлы һәм иҗаты турында чыгыш ясап, II дәрәҗә диплом белән бүләкләнде. Виканы һәм аның җитәкчесе **Гөлнур апа Кадырованы** зур уңышлары белән тәбрик итәбез!

/Безнең спорт/




## Фаил – Россиядә икенче!

Октябрь ае шахмат дөньясында үз эзен калдырды. 1 октябрь көнне Аксубай районы җыелма командасы составында укучыбыз **Фаил Гафиятуллин** Яр Чаллыда узган тиз шахмат буенча ТР команда чемпионатында катнашты. Соңгы турда җиңүе белән Фаил командага бронза медаль китерде.

Фаил өчен 3-10 октябрьдә шахмат турниры Самара өлкәсендә дәвам итте. 39 команда составында илнең 23 төбәгеннән 170 шахматчы катнашты. Татарстаннан да 5 коллектив көч сынашты. Фаил Гафиятуллин очрашулар нәтиҗәләре буенча 13 яшькәчә малайлар арасында 2 урынны яулады. Самара өлкәсеннән ул грамота һәм Россия шахмат федерациясе медале белән кайтты.

Афәрин, Фаил!


**Газетаны гамәлгә куючы** – Түбән Майна урта мәктәбе
**Мөхәррир** – Фәнүзә Гафиятуллина
**Редколлегия әгъзалары:** Әминә Туктамышева, Виктория Нукина, Зөлфирә Сафиуллина

*/Безнең бәйрәмнәр/*



## 1 нче октябрь – өлкәннәр көне

Бүген дөнья Халыкара өлкәннәр көнен билгеләп үтә. Бу көнне мәктәптә эшләп чыккан барлык пенсионерларга – ветераннарыбызга ихтирам белдерү һәм кайгыртучанлык күрсәтү матур традициягә әйләнде. Елның бер көнендә генә түгел, ә ел әйләнәсендә өлкәннәрне игътибар һәм кайгыртучанлык белән җылыту, аларга рухи таяныч булу – безнең олы бурычыбыз.

Хөрмәтле өлкәннәребез! Гомер көзләрегездә урыныгыз түрдән, табыннарыгыз мул, ризыкларыгыз бәрәкәтле, күңелләрегез тыныч, тәннәрегез сау-сәламәт булсын. Авыр елларда бирешмичә эшләп, хезмәтне яратып, бүген дә тормыштан тәм табып яшисез. Тормыш авырлыкларында чыныккан иңнәрегез, сабырлыгыгыз безгә үрнәк. Чәчләрегезгә чал керсә дә, сез безнең өчен иң сөйкемле, иң газиз, иң кадерле затлар. Киләчәктә дә алтын киңәшләрегезне биреп, безгә юл күрсәтеп яшәсәгез иде.

*Әминә Туктамышева, XI сыйныф укучысы*

## 20 нче октябрь – пешекчеләр көне

20 нче октябрь – елның иң тәмле көне! Хөрмәтле пешекчеләребез! Бүген сезне чын күңелдән һөнәри бәйрәмегез белән котлыйбыз. Сезнең хезмәт – мәңгелек һөнәрләрнең берсе. Сез әзерләгән тәмле ризыклар белән тукланмасак, көнебез бушка узар иде. Чөнки тамагы тук укучылар гына яхшы итеп укый ала.

Безнең ашханәне район күләмендә дә мактап кына телгә алалар. Укучылар да һәрвакыт барлык ашханәне сезнең табыннар, сез пешергән ризыклар белән чагыштыра. Ә Сез өстенлектә! Безнең ашханәдә һәрвакыт бәйрәм рухы. Чисталыктан да балкып тора. Үзегез елмайган, ризыгыгыз зәвык белән, күңел җылысы кушып пешерелгәнгә күрә шулай ул.

Хөрмәтле Илсөяр апа, Айгөл апа! Һәрвакыт күңелегез белән елмаеп яшәргә язсын. Сез пешергән ризыклар һәрвакыт өстәлләребезне бизәсен. Укучыларның, әти-әниләрнең рәхмәтен ишетеп, озак еллар эшләвегезне телибез. Сау-сәламәт булыгыз, гаиләгезгә иминлек, тынычлык телибез!

*"Мәктәп хәбәрчесе" редколлегиясе*



## Уңыш бәйрәме – 2022




Безнең мәктәптә уңыш бәйрәме һәрвакыт башкаларыннан аерылып тора. Быелгы көз бәйрәме дә шулай узды.

27нче октябрь көнне мәдәният йортында түбән сыйныфлар бәйрәме узды. Укучылар күзгә муллыкны күрсәткән бик матур күргәзмә оештырдылар. Пешекче апалар бәйрәмчә өстәл әзерләделәр. Сәхнәне матур итеп бизәп, әти-әниләр белән берлектә, бәйрәм тамашасы уздырылды. Балалар ялган көзбикәнең хәйләсен ачып, төлкегә дуслыкның нигезен төшендерделәр.

Өлкән сыйныф укучылары уңыш бәйрәмендә гадәттә КВН уздыралар. Читтәге авылдашлар да бу тамашаны карарга кайталар. Быел укучылар "Гәүһәр" һәм "Аккошлар" командаларына бүленеп ярыштылар. Биремнәр исем сайлау, девиз табу, танышту алымнары, җыр, реклама, биюләр, клип, театр өзекләреннән тора иде. Һәрбер биремне КВНчылар чын сәхнә кешеләредәй, оста башкардылар. Иң авыр хезмәт бәйрәмне бәяләүчеләргә булгандыр. Чөнки һәр команданың чыгышы бик оста әзерләнгән иде. Ахыргы нәтиҗәләр буенча, тамашачылар теләге белән, ике командага да тигез баллар куелды.

*Ләйсән Закирова, V сыйныф укучысы*

*/Котлыйбыз!/*



Октябрьдә дөньяга килгән дусларыбыз **Хафизов Илфатны** (I сыйныф), **Закиров Инсафны** (II сыйныф), **Хабибрахманова Хәнифәне** (VI сыйныф), VII сыйныфтан **Нургалиева Ләйләне** (VII сыйныф), **Галимов Рияз** белән **Хабибрахманов Әхмәтне** (IX сыйныф) чын күңелдән туган көннәре белән котлыйбыз. Аларга тырыш һәм тәртипле укучылар булып, хыялларына ирешүләрен телибез.

Мәктәп хезмәткәрләреннән башлангыч сыйныфлар укытучысы **Камалова Сирин апа** белән оператор **Хәснуллин Азат абыйны** гомер бәйрәмнәре белән котлап, ныклы сәламәтлек, гаилә иминлеге, бәрәкәтле тормыш теләп калабыз.

## Һөнәргә тугрылык

*/Күренекле шәхесләр/*



*Ризидә апа үзе җитәкләгән сыйныф белән. 1990 нчы ел.*

Укытучылар бәйрәме уңаннан, газитебез битләрендә озак еллар буе балаларга белем һәм тәрбия биргән ветеран укытучыларыбызга аерым урын бирергә тырышабыз. Аларның хезмәте – бәяләп бетермәслек хәзинә. Бу санда озак еллар буе мәктәптә төп фәннәрдән булган математиканы укыткан мөгаллимәбез ***Ризидә апа Хәсәнова*** белән әңгәмәне китерергә булдык.

**- Ризидә апа, иң элек шундый сорау: Укытучылык нинди һөнәр ул?**

- Укытучы – абруйлы хезмәт. Әмма бар кеше дә укытучы була алмый. Аның өчен күпмедер дәрәҗәдә тумыштан бирелгән халәт тә кирәктер, минемчә. Үзем горурланып: "Мин бу һөнәргә кечкенәдән килдем" – дип әйтә алам. Бала вакытыннан ук әниемнең нинди һөнәр иясе икәнен күреп үстем. Аның дәфтәр тикшергәннәренә кызыгып күзәтә идем. Ул күрмәгәндә мин дә тикшереп куярга тырыша идем. Аннан соң әниемнең бертуганнары физика - математика укытучылары иде. Абыем да математиканы әйбәт белә иде. Күрше малайлары өй эшләрен аңардан сорап керә иделәр. Ул аларга аңлатканны кызыгып тыңлап тора идем.

**- Сез укытучы һөнәренә кайда укыдыгыз?**

- Мин Иске Әдәм урта мәктәбен 1979 нчы елда тәмамлагач, Казанга документлар тапшырырга киттем. Әниемнең энесе Наил абыйларга тукталдым. Миннән кем булырга теләвемне сорагач,"минем укытучы буласым килә дә, әни табибә-врач булырга өнди" – дидем. Наил абый: "Теләгең шундый булгач, укытучы бул инде" – диде. Шулай итеп булачак һөнәремне үзләштерер өчен Казан дәүләт педагогоия иститутының физика-математика факультетына документларымны тапшырдым.

**- Ул чорда укып һөнәр алгач, белгечләр җитмәгән эш урыннарына билгеләү тәртибе булган. Сезнең тәүге дәресләрегезне кайсы мәктәп укучылары алды?**

- 1983 нче елда институтны тәмамлаганда, Тукай районына эшкә билгеләнгән идем. Тик туган авылдан аерыласым килмәде. Деканга кереп шул турыда сорадым. Ул үтенечемне кире какмады. Шулай итеп мин шул елны ук үзем тәмамлаган мәктәпкә эшкә кайттым. Беренче укучыларым шунда булды.

**- Укып бетерүгә эшкә килгәч, дәрес өлгесе итеп кемнең дәресләрен куя идегез?**

- Үзем белем алган мәктәпкә кайткач, яраткан укытучыларым Лиза апа, Әлфия апа, Эльвира апа, Гомәр һәм Рөстәм абыйларның такта янында аңлаткан дәресләрен үрнәк итеп алдым. Алар кебек буласым килде.

Аннан соң Майнага күчкәч тә, янымда көчле укытучылар иде. Лилия апа, Замир абыйлар, Рафик абый, Ильһамия, Сәкинә апаларыгыз белән бергәләшеп эшләдек. Ул вакытта бер-беребезнең дәресләренә кереп тәҗрибәләр туплый идек. Алар белән бергә без көчле коллектив булдыра алдык. Шуңа хәзер дә сөенәм.

**- Ризидә апа, укытучы һөнәренең нечкәлекләре бардыр инде. Сезне менә шул еллар балалар белән эшләү арытмадымы?**

- Юк, андый уй башка да килмәде. Балаларны һәм фәнемне яратып эшләдем. Әлбәттә, укучылар белән аралашу, белем бирү, аларга үрнәк булу – болар бар да көч сорый укытучыдан. Мин бит үз эшемне теләп башкардым.

**- Сез бит әле директор урынбасары булып та шактый эшләдегез дип беләбез. Төп фән укытып, тагын җитәкчелек тә алып баргансыз. Гаилә, балаларыгыз да бар бит әле.**

- Яраткан эшеңдә эшләсәң, җиңел буладыр дип уйлыйм. Яратуга тырышлык та кушарга инде. Җаваплылык тоеп, җиренә җиткереп эшләргә тырыштым. Укытучылар белән бердәм рәвештә, аңлашып эшләдек.

**- Әйтегез әле, Ризедә апа, кире һөнәр сайлау мөмкинлеге бирелеп, 15 яшьлек вакытыгызга кайтсагыз, табип булыр идегезме.**

- Юк, уйламыйча да укытучы һөнәрен сайлар идем. Еллар үткән саен һөнәрләр алмашына тора. Кайберләре юкка да чыга. Тик кешелек өчен безнең һөнәр ияләре һәрвакыт кирәк булачак. Барлык балаларга тырышып гыйлем туплагыз диясем килә. Юкка гына бишектән алып гомер азагына кадәр белем туплагыз диелмәгән.

Укытучыларга уңышлар телим, сабырлык һәм көч, үз һөнәрләренә тугры булуларын теләр идем. Ә балалар вакытларын бушка уздырмыйча кирәкле белем алып, кеше булсыннар диясем килә.

**- Әңгәмәгез өчен зур рәхмәт, Ризидә апа. Мәктәп белән араны өзмичә, сәламәтлектә, тынычлыкта яшәгез!**

*Әңгәмәне Зөлфирә Сафиуллина алып барды*